ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы территориясендә яшьләрнең хәле һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты доклады хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә яшьләрнең хәле һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты докладын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларына яшьләр хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы законнарны гамәлгә ашыруны тикшереп тору эшен дәвам итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына балалар тәрбияләүдә гаиләнең ролен арттыруга, гаилә кыйммәтләрен һәм милли гореф-гадәтләрне саклап калуга һәм ныгытуга, үсеп килүче буынны хезмәт белән тәрбияләү һәм эшче һөнәрләрне үзләштерүдә яшьләрнең активлыгын арттыру өчен шартлар булдыру мәсьәләләрен хәл итүгә юнәлдерелгән яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны камилләштерү чараларын күрүне тәкъдим итәргә.

4. Республика башкарма хакимияте органнарына, муниципаль берәмлекләр башлыкларына Татарстан Республикасы территориясендә яшьләрнең хәле һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты докладындагы тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру чараларын күрүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 8 июне
№ 1978-VI ДС